ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ярулина, д.7а, с.Малая Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422173

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яруллин ур., 7а йорт, Кече Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422173

тел.(факс): (85563) 3-07-03; e-mail: : Sun.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР
25 декабрь 2025 ел

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ 41

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы Сон авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон белән,2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Сон авыл җирлеге гражданнарының карарларын тормышка ашыру максатыннан
2025 нчы елның 12 ноябрендә кабул ителгән 1 нче номерлы "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге составына керүче Урта Сон торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында;
2025 нчы елның 12 ноябрендә кабул ителгән 2 нче номерлы "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге составына керүче Урта Сон торак пунктында 2026 елга үзарасалым кертү турында";
2025 нчы елның 12 ноябрендә кабул ителгән 3 нче номерлы "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге составына керүче Кече Сон торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында;
2025 нчы елның 12 ноябрендә кабул ителгән 4 нче номерлы "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге составына керүче Кече Сон торак пунктында 2026 елга үзарасалым кертү турында";
2025 нчы елның 13 ноябрендә кабул ителгән 5 нче номерлы "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге составына керүче Югары Сон торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында;
2025 нчы елның 13 ноябрендә кабул ителгән 6 нче номерлы "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге составына керүче Югары Сон торак пунктында 2026 елга үзарасалым кертү турында";
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге башкарма комитеты К а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Сон авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Җитәкче: /Р.Ф.Мөхәммәтҗанов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Сон авыл җирлеге Башкарма комитетының
25.12.2025 ел, 41 санлы карарына
1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Сон авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2026 елның 25 мартына кадәр үзара салым акчаларын җирле гражданнар җыенында катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 төркем инвалидлар, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары( хатыны һәм 18 яшькә кадәр булган балалары), көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, түли.

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, җиткерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Сон авыл җирлеге Башкарма комитетының
25.12.2025 ел, 41 санлы карарына
2 нче кушымта

______________________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*

бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № ______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
________________________________________________________________
______________________________________________________

Адрес: _______________________________________________
Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең __________ авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2026 нче елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 25.03.2026 елга кадәр халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр ________ сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:
Кабул итүче як банкы БИК ____________________________________
Сч. № ________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № _____________________________________
ИНН _____________________________________
КПП _____________________________________
КБК ______________ ОКАТО ______________
Түләүнең билгеләнеше: гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче ________________________________________________
П. У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -
____________________________________________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*
___________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) №
Түләүченең Ф.И.Ә.и.
________________________________________________
Адрес:___________________________________________
«__» 20 г.
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегү шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)___________
авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.